**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ФОМКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ФОМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Фома ав. **КАРАР**

« 29 » октябрь 2020 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Фома авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 9 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Фома авылы Мәктәп урамы, 15нче йорт адресы бенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы Спутник урамы 1-29нчы, Чапаев урамы 1-85нче, Елга урамы 1-46нчы, К.Маркс урамы 2-90нчы йортлардан йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Фома авылы Мәктәп урамы, 15нче йорт адресы бенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы Мәктәп урамы 1-53нче, Совет урамы 1-45нче, Дуслык урамы 2-82нче йортлардан йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Фома авылы Мәктәп урамы, 15нче йорт адресы бенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы Тукая урамы 1-57нче, Яшьләр урамы 1-7нче, Гагарин урамы 1-37нче йортлардан йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен Фома авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәүче балигъ булган, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәкләрдән кала, һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

- торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунт - вак таш түшәү;
- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү»

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов